**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

**Аларны гамәлгә ашыру өчен җир кишәрлекләрен сатуга куймыйча арендага бирү рөхсәт ителгән масштаблы инвестиция проектлары туры килергә тиешле критерийларның сыйфат һәм сан күрсәткечләренә үзгәреш кертү турында**

Намуссыз төзүчеләр гамәлләреннән (гамәл кылмауларыннан) зыян күргән гражданнар – күпфатирлы йортлар төзүдә өлешле катнашучыларның хокукларын яклау ысулларын камилләштерү максатларында, Татарстан Республикасы Җир кодексының $33^3$ статьясы нигезендә **карар бирәм**:

1. Аларны гамәлгә ашыру өчен җир кишәрлекләрен сатуга куймыйча арендага бирү рөхсәт ителгән масштаблы инвестиция проектлары туры килергә тиешле критерийларның Татарстан Республикасы Президентының «Аларны гамәлгә ашыру өчен җир кишәрлекләрен сатуга куймыйча арендага бирү рөхсәт ителгән масштаблы инвестиция проектлары туры килергә тиешле критерийларның сыйфат һәм сан күрсәткечләрен билгеләү турында» 2015 елның 7 декабрендәге ПУ-1170 номерлы Указы белән (Татарстан Республикасы Президентының 2016 елның 3 ноябрендәге ПУ-981 номерлы Указы нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) билгеләнгән сыйфат һәм сан күрсәткечләренә, «Намуссыз төзүчеләр гамәлләреннән (гамәл кылмауларыннан) зыян күргән гражданнар – күпфатирлы йортлар төзүдә өлешле катнашучыларның хокукларын яклау буенча чаралар күрү максатларында шәхси торак йортлар һәм (яисә) күпфатирлы йортлар төзү» юлын түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

| | |
|---|---|
| «Намуссыз төзүчеләр гамәлләреннән (гамәл кылмауларыннан) зыян күргән гражданнар – күпфатирлы йортлар төзүдә өлешле катнашучыларның (алга таба – зыян күргән гражданнар) хокукларын яклау буенча чаралар күрү максатларында | Инвестиция проектында торак урыннарның гомуми мәйданы кимендә 10 мең квадрат метр булган күпфатирлы йорт (күпфатирлы йортлар) төзү һәм Татарстан Республикасы территориясендә зыян күргән гражданнарның хокукларын яклау буенча түбәндәге чараларның берсен күрү күздә тотыла:<br>инвестиция проектында төзелеше күздә тотылган торак урыннар гомуми мәйданының кимендә 10 процентына тигез булган мәйдандагы торак урыннарны зыян күргән |

| | |
|---|---|
| шәхси торак йортлар һәм (яисә) күпфатирлы йортлар төзү | гражданнар милкенә тапшыру;<br>аңа тотыла торган чыгымнар кимендә 50 миллион сум тәшкил иткән өлешле төзелештә катнашучылар акчасын файдаланып төзелә торган, намуссыз төзүчеләр төзеп бетермәгән күпфатирлы йорт (күпфатирлы йортлар) төзелешен тәмамлау |

».

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына:

территорияләрендә зыян күргән гражданнарның хокукларын яклау буенча чаралар күрү ихтыяҗы кирәк булган Татарстан Республикасы шәһәр округлары һәм муниципаль районнары башлыклары белән берлектә, Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнары һәм җирле үзидарә органнарының зыян күргән гражданнарның хокукларын яклау буенча чараларны гамәлгә ашыруда катнашырга карар кабул иткән инвестор белән үзара хезмәттәшлек регламентын билгеләргә;

үз актларын әлеге Указга туры китерергә, шулай ук аны гамәлгә ашыруны тәэмин итүче башка карарлар кабул итәргә.

3. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

Казан,Кремль
2016 ел, 14 ноябрь
№ ПУ-1004